**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№11787**
**04.12.2023**

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә җылылык белән тәэмин итү системасында оператив-диспетчерлык идарәсе механизмын раслау турында

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеген җылылык белән тотрыклы тәэмин итү, оператив мәгълүмат алу, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә җылылык белән тәэмин итү объектларының һәм системасының ышанычлылыгын контрольдә тоту максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Энергетика министрлыгының «Җылыту чорына әзерлекне бәяләү кагыйдәләрен раслау турында» 2013 елның 12 мартындагы  103 номерлы Приказы нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә җылылык белән тәэмин итү системасында оператив-диспетчерлык идарәсе механизмын кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2023 елның 4 декабрендәге
11787 номерлы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә
җылылык белән тәэмин итү системасында оператив-диспетчерлык идарәсе
механизмы

1. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә җылылык белән тәэмин итү системасында оператив-диспетчерлык идарәсе механизмы (алга таба – механизм) җылылык белән тәэмин итүче оешмаларның, идарәче оешмаларның оператив-диспетчерлык хезмәтләренең һәм җылылык энергиясен кулланучыларның җылылык белән тәэмин итү мәсьәләләре буенча үзара эшчәнлеген билгели.

2. Күрсәтелгән оешмаларның төп бурычы булып җылылык челтәрләренең һәм җылылык куллану системаларының тотрыклы һәм өзлексез эшләвен тәэмин итү, җылылык белән тәэмин итүнең билгеләнгән режимнарын саклау, җылылык чыганакларында, җылылык челтәрләрендә һәм җылылык куллану системаларында аварияләрне кисәтү, локальләштерү һәм бетерү буенча оператив чаралар күрү тора.

3. Файдалану җаваплылыгы чикләрендә кулланучыларны җылылык белән тәэмин итә торган, күпфатирлы йортларның гомуми мөлкәтен ремонтлауны һәм карап тотуны гамәлгә ашыра торган барлык җылылык белән тәэмин итүче оешмаларның, идарәче оешмаларның тәүлек буе эшләүче оператив-диспетчерлык хезмәтләре булырга тиеш. Штат расписаниеләре белән мондый хезмәтләр каралмаган оешмаларда оператив җитәкчелек вазыйфалары тиешле приказ белән билгеләнгән затка яисә оешма җитәкчесенә йөкләнә.

4. Җылылык белән тәэмин итүнең локаль системасын эксплуатацияләү буенча оператив-диспетчерлык хезмәтләренең гамәлләрен гомуми координацияләүне җылылык белән тәэмин итүче оешма, авария очрагын локальләштерү һәм бетерү буенча – эксплуатация җаваплылыгы чикләрендә авария очрагы барлыкка килгән оешманың оператив-диспетчерлык хезмәте гамәлгә ашыра.

5. Җылылык белән тәэмин итүне озакка туктатып торуга китерә торган күләмле эшләр булган очракта, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең гадәттән тыш хәлләр һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе боерыгы белән, торгызу эшләренә законнарда билгеләнгән тәртиптә махсуслаштырылган төзелеш-монтаж һәм башка предприятиеләр җәлеп ителә.

2. Энергия белән тәэмин итү чыганакларында, энергия куллану челтәрләрендә һәм системаларында аварияләр килеп чыкканда һәм бетерелгәндә оператив-диспетчерлык һәм авария-торгызу хезмәтләренең үзара эшчәнлеге

6. Авария килеп чыгу, кулланучыларны энергия белән тәэмин итүдән өзү яки чикләү турында хәбәр алганда, тиешле оешма диспетчеры авария урынында куркынычсызлыкны тәэмин итү (киртәләү, яктырту, саклау һ.б.) буенча оператив чаралар күрә һәм авария очракларын бетерү буенча инструкция нигезендә эш итә.

7. Авария очрагы барлыкка килү турында, аны локальләштерү һәм бетерү буенча кабул ителгән карар турында диспетчер кичекмәстән оешма җитәкчесенә, үз җиһазларын һәм коммуникацияләрен үзгәртергә яки туктатырга кирәк булган оешмалар

диспетчерларына, кулланучыларның диспетчерлык хезмәтләренә хәбәр итә. Шулай ук, авария очрагы барлыкка килү һәм кулланучыларны җылылык белән тәэмин итүне торгызу вакыты турында мәҗбүри тәртиптә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең Бердәм дежур-диспетчерлык хезмәтенә (алга таба – БДДХ тел. 112) хәбәр итә.

8. Йорт эчендәге җылылык белән тәэмин итү инженерлык челтәрләрендә авария килеп чыкканда, җылылык белән тәэмин итүче оешма диспетчеры бу хакта кичекмәстән БДДХга һәм күпфатирлы йорттагы гомуми мөлкәтне карап тотуны гамәлгә ашыра торган идарәче оешманың җаваплы затына хәбәр итә.

9. Кулланучыларга җылылык энергиясен чикләү яки өзү режимын кертү турындагы карар, Кулланучыларга һәм шәһәр Башкарма комитетына хәбәр итеп, җылылык белән тәэмин итүче оешмалар җитәкчеләре тарафыннан кабул ителә.

10. Җылылык белән тәэмин итү һәм җылылык куллану системаларын өзү һәм бушату турындагы командалар диспетчерлык хезмәтенең элемтә каналлары аша уза.

11. Авария нәтиҗәсендә кешеләр тормышына, җиһазлар, инженерлык коммуникацияләре яки төзелешләр җимерелү куркынычы янаган очракта, җылылык белән тәэмин итүче оешмаларның диспетчерлары, килештермичә, җиһазларны эштән туктату турында боерык бирәләр, ләкин өзәр алдыннан һәм авария хәлендәге җылылык-механик җиһазларны яки җылылык челтәрләре участокларын ремонтлау-торгызу эшләре тәмамланганнан соң, мәҗбүри рәвештә кичекмәстән БДДХга һәм Кулланучыларга хәбәр итәләр.

12. Аварияне бетерү өчен җаваплы зат, 3 пункт нигезендә түбәндәгеләргә бурычлы:

1) кирәк булганда, авария-торгызу эшләрен оештыру өчен, авария урынында коммуникацияләре яки корылмалары булган оешмаларның һәм ведомстволарның тиешле вәкилләрен диспетчерлык хезмәтләре аша чакырырга;

2) авария-торгызу эшләрен башкаруны оештырырга һәм эшләр башкаруның куркынычсыз шартларын тәэмин итәргә;

3) авария-торгызу эшләре (яки нинди дә булса этабы) тәмамлангач, эш схемасын, җылылык белән тәэмин итүнең билгеләнгән параметрларын торгызу һәм эшләтеп җибәрү программасы нигезендә кулланучыларны тоташтыру өчен, тиешле диспетчерлык хезмәтләренә мәгълүмат бирергә.

13. Авария килеп чыккан урында үз коммуникацияләре яки корылмалары булган барлык милек формаларындагы оешмалар һәм предприятиеләр, җылылык белән тәэмин итүче оешма диспетчерының чакыруы буенча, аварияне бетерү эшләрен башкару шартларын килештерү өчен, тәүлекнең теләсә кайсы вакытында бер сәгать эчендә үз вәкилләрен җибәрергә тиеш.

## 3. Энергия белән тәэмин итү системаларын эксплуатацияләгәндә оператив-диспетчерлык хезмәтләренең үзара эшчәнлеге

14. Кулланучыларны планлы өзүне (җылылык йөрткеч параметрларын үзгәртүне) раслау өчен, җылылык белән тәэмин итүче оешмаларның диспетчерлык хезмәтләре билгеләнгән эшләргә кадәр 10 көн алдан БДДХга, шәһәр Башкарма комитетына һәм кулланучыларга хәбәр итә.

15. Кулланучылар (юридик затлар) балансындагы җиһазларны план буенча ремонтлауга чыгару, билгеләнгән эшләргә кадәр 10 көн алдан, мәҗбүри рәвештә БДДХга, шәһәр Башкарма комитетына хәбәр итеп башкарыла.

16. Котельныйларга салкын су бирүне озак вакытка туктатуга китергән аварияләр булганда, җылылык белән тәэмин итүче оешма диспетчеры БДДХга хәбәр итеп, аны тулысынча туктатып, кулланучыларны салкын су белән тәэмин итүне чикләүне кертә.

17. Электр челтәрләрендә һәм ярдәмче трансформатор станцияләрдә җылылык белән тәэмин итү системасы объектларына электр энергиясе бирүне чикләүгә яки туктатуга китерә торган планлы яки авария-торгызу эшләрен үткәргәндә, әлеге электр

челтәрләре һәм ярдәмче трансформатор станцияләре аның карамагында булган оешма диспетчеры, эшләр башлану һәм тәмамлану срокларын күрсәтеп, әлеге өзүләр турында 10 көн эчендә яки кичекмәстән җылылык белән тәэмин итүче тиешле оешма диспетчерына һәм БДДХның оператив дежурына хәбәр итәргә тиеш.

18. Тышкы һава температурасы җылылык белән тәэмин итү системасының җылылык чыганакларында җылылык генерацияләү куәтләре җитми торган күрсәткечләргә кадәр түбәнәйгән очракларда, җылылык белән тәэмин итүче оешма диспетчеры, шәһәр Башкарма комитеты белән килештереп, бер үк вакытта БДДХга хәбәр итеп, Кулланучыларга җылылык энергиясен җибәрүне чикләүне кертә.

19. Яңа объектларны тоташтыру бары тик Федераль экологик, технологик һәм атом күзәтчелеге хезмәте (Ростехнадзор) һәм җылылык белән тәэмин итүче оешма рөхсәте буенча, шул ук вакытта шәһәр Башкарма комитетына хәбәр итеп башкарыла.

20. Кулланучының язмача заявкасы буенча ремонтка чыгарылган объектларны тоташтыру, заявкада күрсәтелгән кулланучының җаваплы заты үтенече буенча, җылылык белән тәэмин итүче оешмалар рөхсәте нигезенә башкарыла. Заявкалар буенча эшләр тәмамланганнан соң, югарыда күрсәтелгән предприятиеләрнең һәм оешмаларның оператив җитәкчеләре БДДХга хәбәр итә.

## 4. Техник документлар

21. Җылылык белән тәэмин итүче оешмаларның һәм җылылык энергиясен кулланучыларның оператив-диспетчерлык хезмәтләре арасындагы үзара мөнәсәбәтләрне билгеләүче документлар булып түбәндәгеләр тора: әлеге Механизм; җылылык генерацияләү җайланмаларын, җылылык челтәрләрен һәм җылылык кулланучы җайланмаларны эксплуатацияләү һәм куркынычсызлык техникасы буенча гамәлдәге норматив-техник документлар; гамәлдәге норматив-техник документларны исәпкә алып эшләнгән мондый җиһазларны эксплуатацияләүнең эчке инструкцияләре һәм куркынычсызлык техникасы; җылылык белән тәэмин итүче предприятиеләр җитәкчеләре тарафыннан расланган Җылылык энергиясе җайланмаларындагы аварияләрне һәм гадәттән тыш хәлләрне бетерү буенча авария-ремонт бригадаларының эш итү планнары. Электр белән тәэмин итү чыганакларында вакытлыча җылылык энергиясе, электр куәте яки ягулык җитешмәгәндә, эчке инструкцияләр аварияләр, чикләүләр һәм өзүләр вакытында оператив эш итүләрнең җентекләп эшләнгән планын үз эченә алырга тиеш. Инструкцияләргә авариягә бәйле мөмкин булган үзгәртеп тоташтыруларның схемалары теркәлергә, кайнар су һәм җылылык белән тәэмин итүне өзү, җылылык челтәрләрен һәм бинаның җылылык куллану системаларын бушату, соңыннан аларны тутыру һәм, аварияле режимнарның эшләнгән вариантлары булганда, эшләтеп җибәрү тәртибе күрсәтелергә, җылылык белән тәэмин итүнең көчәйтелгән һәм исәп-хисап режимнарында персоналның дежур торуын һәм эш итүен оештыру билгеләнергә тиеш. Һәр оешмада кирәкле эксплуатация документларының конкрет исемлеге аның җитәкчелеге тарафыннан билгеләнә.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева